**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ВЯЗОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 3**

Вязовка бистәсе «20» май 2019 ел

**Вязовка авыл җирлеге Советының**
**2019 елның 14 февралендә булып узган**
**XXXVI сессиясендә кабул ителгән**
**“Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы**
**“Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә**
**гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышуы)**
**оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы**
**Нигезләмәне раслау хакында”гы 5нче карарга**
**үзгәрешләр кертү турында**

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы №131-ФЗ законга үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Вязовка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып

**Вязовка авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

Вязовка авыл җирлеге Советының 2019 елның 14 февралендә булып узган XXXVI сессиясендә кабул ителгән “Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать тикшерүе) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында”гы Нигезләмәне раслау хакында”гы 3нче карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 4нче бүлектә:

*- 4нче пунктны яңа басмада бәян итәргә:*

«4. Гавами тыңлаулар халык, Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Советы, Бөгелмә муниципаль районы “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы (“Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла.

Халык, Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган гавами тыңлаулар Акбаш авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә, ә “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль

берәмлеге башлыгы (“Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе) инициативасы буенча уздырыла торганы – “Вязовка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башлыгы тарафыннан билгеләнә.

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Вязовка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **В.Н.Соколов**